| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 22.01.2020 | Казан шәһәре | № 8 |

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 19 мартындагы 35 номерлы боерыгы белән расланган Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәрне һәм аларның эчтәлеген рәсмиләштерү һәм газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаучы, тимер юллар аша ташу өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәтләр күрсәтү һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә эшчәнлек башкаручы табигый монополия субъектлары тарафыннан, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 883 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 19 мартындагы 35 номерлы боерыгы белән расланган Юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәрне һәм аларның эчтәлеген рәсмиләштерү һәм газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаучы, тимер юллар аша ташу өлкәсендә, транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәтләр күрсәтү һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә эшчәнлек башкаручы табигый монополия субъектлары тарафыннан, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче

оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан рәсмиләштерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыру өчен җайга салынулы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) уздыруга Дәүләт комитетының түбәндәге структур бүлекчәләренең вәкаләтле вазыйфаи затлары җаваплы булып тора:

1) коммуналь өлкә оешмаларын мониторинглау бүлеге, түбәндәгеләргә карата:

а) кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар;

б) җылылык белән тәэмин итүче оешмалар;

в) җылылык челтәрләре оешмалары;

г) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары;

д) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар;

2) электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектларына карата - электр энергиясе тарифларын җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге;

3) технологик ялгау өчен түләүне җайга салу һәм тикшерүдә тоту бүлеге, түбәндәгеләргә карата:

а) җылылык белән тәэмин итүче оешмалар;

б) җылылык челтәрләре оешмалары;

в) кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмалар;

г) салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар;

д) Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыручы табигый монополия субъектлары;

е) электр челтәрләре оешмалары;

4) сәнәгать булмаган өлкә тарифларын җайга салу һәм тикшерүдә тоту бүлеге, түбәндәгеләргә карата:

а) тимер юл аша ташу өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополия субъектлары;

б) транспорт терминалларында, портларда һәм аэропортларда хезмәтләр күрсәтү һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану буенча хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә эшчәнлек башкаручы табигый монополия субъектлары;

5) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы 1) - 4) пунктчаларында күрсәтелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата, шулай ук административ хокук бозулар турында эшләр кузгату һәм административ хокук бозган затларны административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өлешендә дә, контроль-ревизия бүлеге.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев